ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ,
ӘЙЛӘНЕШЕ ҺӘМ СЫЙФАТЫ
ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ
ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясе)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

БОЕРЫК

Казан ш.

05.08.2019 №10-07/141/под-1089/19

Татарстан Республикасы
территориясендә урнашкан гомуми
белем бирү оешмаларының 8-11
сыйныф укучылары арасында
«Кулланучыларның хокукларын
яклау» темасына республика
олимпиадасын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклауның комплекслы системасын үстерү» ярдәмче программасына кушымтаның 2.1 пункты нигезендә, боерык бирәбез:

1. «Кулланучыларның хокукларын яклау» темасы буенча республика олимпиадасын оештыру һәм уздыру турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) расларга (кушымтада бирелә).
2. Расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары арасында «Кулланучыларның хокукларын яклау» темасына республика олимпиадасын оештырырга һәм уздырырга.

3. Боерыкны муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының мәгариф идарәсе органнары җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең эчке базарны үстерү һәм координацияләү бүлеге башлыгына, Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органнары башлыкларына, Олимпиаданы оештыру комитеты әгъзаларына җиткерергә.

4. Әлеге Боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары Ф.Г.Хәмматовка һәм Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары А.М.Әсәдуллинага йөкләргә.

Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе җитәкчесе

_______________Җ.Й.Әхмәтханов

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры

_______________________ Р.Т.Борһанов

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2019 елның 5 августындагы 10-07/141/под-1089/19 номерлы боерыгы белән расланды

**«Кулланучыларның хокукларын яклау» темасы буенча республика олимпиадасын оештыру һәм уздыру турында нигезләмә**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Кулланучыларның хокукларын яклау» темасы буенча республика олимпиадасы (алга таба – Олимпиада) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган 2014-2021 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш дәүләт программасының (алга таба – Программа) «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклауның комплекслы системасын үстерү» ярдәмче программасына кушымтаның 2.1 пункты нигезендә уздырыла.

1.2. Әлеге Нигезләмә Олимпиада максатларын һәм бурычларын, аны уздыру тәртибен, оештыру-методик тәэмин итүне, катнашу шартларын, катнашу өчен гариза формаларын, шулай ук җиңүчеләрне, призерларны, номинантларны билгеләү тәртибен, аларны бүләкләү процедурасын билгели.

1.3. Олимпиаданы үткәрү вакыты – 2019 елның 18 сентябреннән 2019 елның 20 ноябренә кадәр.

1.4. Олимпиада уздыруны оештыруны финанслау Программаны гамәлгә ашыру кысаларында республика бюджеты акчасы хисабына тормышка ашырыла.

## II. ОЛИМПИАДАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Олимпиаданың максаты:

Олимпиаданың максаты – кулланучыларның хокукларын яклау өлкәсендә белемнәрне популярлаштыру, уку йортлары укучыларының товарлар, эшләр һәм хезмәтләр куллану базары мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнүгә мотивациясен арттыру, норматив хокукый актларны белү һәм куллана белү, шулай ук бу өлкәдә укучыларның иҗади потенциалын ачуга ярдәм итү, кулланучы буларак үз

хокукларыңны яклауда мәнфәгатьне арттыру һәм актив гражданлык позициясе булдыру.

2.2. Олимпиаданың бурычлары:

кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнүгә укучыларның мотивациясен арттыру;

укучыларда товарлар, эшләр һәм хезмәтләр куллану базары турында белемнәр, кулланучы буларак үзеңне грамоталы тоту күнекмәләрен, үзеңнең кулланучы хокукларыңны мөстәкыйль яклый белү сәләтен формалаштыру;

гомуми белем бирү оешмалары укучыларында иҗади сәләтләрне ачыклау һәм үстерү, сәләтле балаларга ярдәм итү өчен кирәкле шартлар тудыру, фәнни белемнәрне пропагандалау.

## III. ОЛИМПИАДАНЫ ОЕШТЫРУЧЫЛАР

Олимпиаданы оештыручылар – Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты өлкәсендә дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы.

## IV. ОЛИМПИАДАНЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ УЗДЫРУ ТӘРТИБЕ

4.1. Олимпиадада гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныфларында укучы, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең мәгариф программаларын үзләштерүче, www.tatzpp.ru сайтында теркәлгән укучылар ирекле нигездә катнаша ала (1 нче кушымта). Теркәлү формасын тутыручы Олимпиадада катнашучы теркәлү мәгълүматларының дөреслеге һәм тулылыгы өчен җаваплы була. Үзе турында тулы һәм дөрес булмаган мәгълүмат биргән, шул исәптән уку сыйныфын дөрес күрсәтмәгән укучылар Олимпиадада катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла.

Теркәлү 2019 елның 2 сентябреннән башлап 2019 елның 16 сентябренә кадәрге чорда уздырыла. Теркәлгән Олимпиадада катнашучылар исемлеге 2019 елның 17 сентябрендә www.tatzpp.ru сайтында урнаштырыла.

4.2. Олимпиаданың барлык чаралары да укучыларның шәхси беренчелек өчен дә, команда (мәктәп) беренчелеге өчен дә ярышларыннан гыйбарәт.

4.3. Шәхси беренчелек өчен ярышучы катнашучылар өчен Олимпиада өч этаптан тора:

I этап – башлангыч (сайлап алу) – 2019 елның 18 сентябреннән 23 сентябренә кадәр уздырыла. Теркәлгән катнашучылар тест биремен үтәү рәвешендә I этапны дистанцион рәвештә уза. Тест биремнәрендә 15 сорау була (төрле катлаулылык дәрәҗәсендәге (җиңел, уртача, катлаулы) 5әр сорау) һәм алар 2019 елның 18 сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең www.tatzpp.ru сайтында, «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

Олимпиаданың I этабын узу йомгаклары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең www.tatzpp.ru сайтында 2019 елның 30 сентябрендә «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

II этап – 2019 елның 1 октябреннән 8 октябренә кадәр дистанцион, кулланучыларның хокукларын яклау өлкәсендә бирелгән тематикага эссе формасында иҗат биремен үтәү рәвешендә үткәрелә.

Эссе темалары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең www.tatzpp.ru сайтында 2019 елның 1 октябрендә «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

Олимпиадада катнашучыга «Кулланучыларның хокукларын яклау» темасына кагылышлы конкрет проблема буенча иҗади инша әзерләргә, аның мәгънәсен ачарга, төрле аспектларны билгеләргә, үз мөнәсәбәтен формалаштырырга һәм нигезләргә кирәк. Фикерләрне бәян иткәндә, тиешле төшенчәләрне, шулай ук иҗтимагый тормыш фактларын кулланып, үз фикереңне дәлилләргә кирәк.

Эссе doc яки docx форматында рус яки татар телләрендә, 3 биттән артмаган күләмдә кабул ителә. Форматы – А4. Кырыйлары: сулдан – 3 см, уңнан – 1,5 см, өске өлеше – 2 см, аскы өлеше – 2 см. Сүзләрне күчерергә ярый. Битләренең аскы өлешендә нумерациясен күрсәтү мәҗбүри. Шрифты – Times New Roman, кегль – 14. Юллар арасындагы интервал – бер ярым. Доклад текстын тигезләү – киңлеге буенча.

Конкурсантлардан эшләр түбәндәге электрон почта адресына җибәрелә: Zpp.Olimpiada@tatar.ru.

Олимпиаданың әлеге этабын узу йомгаклары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең www.tatzpp.ru сайтында 2019 елның 17 октябрендә «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

III этап – йомгаклау этабы, турыдан-туры, 2019 елның 28 октябреннән 8 ноябренә кадәр уздырыла.

III этапны үткәрү урыннары һәм конкрет даталары турында мәгълүмат өстәмә рәвештә www.tatzpp.ru сайтында «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

III этап 2 турдан тора.

1 нче тур – язмача формада тест, 2 нче тур – билетлар буенча телдән формада сорау һәм җавап рәвешендә конкурсантлар белән әңгәмә.

Олимпиадада катнашучылар сорау һәм җавап рәвешендә әңгәмәне рус телендә дә, татар телендә дә уза ала.

Шәхси беренчелеккә ярышучылар өчен Олимпиадага йомгак ясау 2019 елның 20 ноябренә кадәр уздырылачак.

III этап кысаларында Олимпиадада катнашучыларны әзерләүне гамәлгә ашыручы педагоглар өчен укыту чаралары үткәрелә.

4.4. Олимпиада биремнәрен бәяләү критерийлары:

4.4.1. I этапның тест биремнәре һәр дөрес җавап өчен сорауларның катлаулылыгы дәрәҗәсенә карап бәяләнә:

«Җиңел» категориясендәге сорауга 1 балл;

«Уртача» категориясендәге сорауга 2 балл;

«Катлаулы» категориясендәге сорауга 3 балл.

I этап өчен максималь балл – 30 балл.

4.4.2. Эссе 3 критерий буенча бәяләнә:

эссе темасының ачыклыгы, эшнең эчтәлегендә проблеманы аңлау дәрәҗәсе (1-10 балл);

фикерләүдә һәм аргументларда теоретик нигезләмәләр, нәтиҗәләр һәм фактик материал куллану (1-10 балл);

иҗади эш эчтәлегендә катнашучының үз позициясен чагылдыруы (1-10 балл).

Олимпиаданың II этабы өчен максималь билге – 30 балл.

4.4.3. III этапның йомгаклау биремнәре түбәндәгечә бәяләнә:

1 нче турның тест соравына һәр дөрес җавап өчен жюри 1 балл (тестта 25 сорау) куя. Тестны чишү өчен катнашучыга 25 минут вакыт бирелә;

2 нче тур соравына җавап (билетта 1 сорау) жюри җавапның төгәллеге һәм тулылыгы өчен 1-10 балл куя (дөрес, аргументлы, норматив-хокукый чыганакларга сылтамалары, мәсьәләне ачуда тормыштан мисаллар китерелгән) куя. Билет Олимпиадада катнашучы тарафыннан «ябык» рәвештә тәкъдим ителгән билетлардан очраклы сайлап алу ысулы белән мөстәкыйль сайлап алына. Әзерләнү өчен 5 минут вакыт бирелә.

Олимпиаданың III этабының 1 нче туры өчен максималь билге – 25 балл.

Олимпиаданың III этабының 2 нче туры өчен максималь билге – 10 балл.

4.5. Шәхси беренчелектә Олимпиада җиңүчеләр, призерлар һәм номинантлар 8-9 сыйныф укучылары һәм 10-11 сыйныф укучылары арасында аерым-аерым билгеләнә. Шәхси беренчелек буенча Олимпиадада җиңүче дип иң күп балл туплаган катнашучылар таныла.

4.6. Олимпиаданың III этабында җиңүче яки призер булмаган, әмма югары нәтиҗәләр күрсәткән (3 дәрәҗә призерлар балларының 70 һәм аннан күбрәк проценты) катнашучылар арасында номинантлар билгеләнә:

«Кулланучы белеме нигезләрен өйрәнүдә ирешкән казанышлары өчен»;

«Кулланучы белеме нигезләрен өйрәнүдә ирешкән уңышлары өчен»;

«Кулланучы белемен арттыруда ныклык һәм үҗәтлек өчен»;

«Кулланучы белемнәрен алуда активлык һәм максатчанлык өчен»;

«Җиңүгә һәм куллану законнарын өйрәнүгә омтылган өчен»;

«Кулланучыларның хокукларын яклау» темасы буенча укучылар өчен Олимпиадада актив катнашкан өчен».

4.7. «Татар телендә кулланучыларның хокукларын өйрәнүдәге уңышлары өчен» дигән аерым номинация ярышларның этапларын татар телендә узарга теләүче Олимпиадада катнашучылар өчен билгеләнә.

4.8. Шәхси ярышларның I һәм II этапларын уңышлы узган һәм Олимпиаданың III йомгаклау этабына чыккан укучылар Олимпиаданың команда ярышларында катнаша ала. Команда составында бер гомуми белем бирү оешмасыннан биш укучы булырга тиеш. 2019 елның 25 октябренә кадәрге чорда команда билгеләнгән форма буенча (3 нче кушымта) катнашу өчен гариза тапшыра.

Олимпиаданың III этабына бер гомуми белем бирү оешмасыннан биштән ким катнашучы узса, команда формалашмый.

Команда беренчелегендә катнашу өчен заявкалар әлеге электрон почта адресына җибәрелә: Zpp.Olimpiada@tatar.ru.

2019 елның 28 октябреннән 8 ноябренә кадәрге чорда командалар ике гамәли вәзгыяти биремне үтәү рәвешендә сынаулар уза.

Команда беренчелеге түбәндәгечә бәяләнә: җавапның төгәл, тулы булуы (1-10 балл).

Команда беренчелеге өчен максималь билге – 20 балл.

Тупланган баллар саны тигез булганда, конкурс биремнәрен үтәүгә сарыф ителгән вакыт исәпкә алына.

Команда беренчелегенә ярышучылар өчен Олимпиадага йомгак ясау 2019 елның 20 ноябренә кадәр уздырылачак.

Команда ярышларында катнашу өчен төрле гомуми белем бирү оешмаларыннан икедән азрак команда формалашса, командалар ярышы барып чыкмаган дип таныла.

4.9. Олимпиадага (шәхси һәм команда беренчелеге) нәтиҗәләр ясау Олимпиадада катнашкан жюри әгъзаларының балл билгеләренә нигезләнеп башкарыла һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа рәислек итүче, җаваплы сәркатип һәм жюри әгъзалары кул куя. Баллар саны тигез булганда, рәислек итүче затның тавышы хәл иткеч булып санала.

Олимпиада йомгаклары турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең www.tatzpp.ru сайтында 2019 елның 20 ноябренә кадәр «Олимпиада» бүлегендә урнаштырыла.

4.10. Олимпиадада катнашучы Олимпиада нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, ул оештыру комитетына апелляция бирергә хокуклы. Апелляция килгән көнне оештыру комитеты аны жюри әгъзаларына җибәрә.

Апелляция https://www.tatzpp.ru сайтында Олимпиада йомгаклары басылып чыкканнан соң өч эш көне эчендә ирекле формада язма рәвештә бирелә.

Жюри әгъзалары апелляцияләр килү вакыты узган көннән соң дүрт эш көне дәвамында аларны бергәләп карый һәм алар турында фикер алыша. Карар ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш туплау нигезендә кабул ителә һәм юриның катнашкан әгъзалары күпчелекне тәшкил иткәндә, легитимлы булып таныла. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүче затның тавышы хәл итүле була. Жюриның җаваплы сәркатибе жюри карары нигезендә беркетмә рәсмиләштерә. Беркетмәдә һәр жюри әгъзасының фикере һәм гомуми нәтиҗә күрсәтелә:

апелляцияне канәгатьләндермәү һәм бастырып чыгарылган нәтиҗәләрне саклау турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәртү турында.

Беркетмәгә рәислек итүче, җаваплы сәркатип һәм жюри әгъзалары кул куя.

Жюри карары апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча ахыргы булып тора, яңадан каралырга тиеш түгел һәм аңа суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.

## V. ОЛИМПИАДАНЫ ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ

5.1. Олимпиада белән гомуми җитәкчелек итү аны оештыру комитеты тарафыннан башкарыла. Оештыру комитетының составы Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, кулланучыларның хокукларын яклау буенча иҗтимагый берләшмәләр, мәгариф учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү мәгариф оешмалары укытучылары вәкилләреннән җиде кешелек составта формалаштырыла.

5.2. Олимпиаданы оештыру комитеты:

Олимпиаданы уздыру регламентын билгели;

Олимпиаданы турыдан-туры уздыруны тәэмин итә;

Олимпиаданың методик комиссиясе һәм жюри составын формалаштыра;

Олимпиада йомгакларын анализлый, гомумиләштерә һәм раслый;

Олимпиадада катнашучыларның апелляцияләрен жюри әгъзаларына җибәрә;

Олимпиадада җиңүчеләрнең, призерларның һәм номинантларның исемлеген раслый;

Олимпиада жюрие карарын беркетмә белән рәсмиләштерә;

Олимпиадада җиңүчеләрне, призерларны һәм номинантларны бүләкли.

5.3. Олимпиаданың методик комиссиясе:

Олимпиада этаплары өчен бирем материалларын әзерли;

Олимпиаданың барлык этапларында башкарылган эшләрне бәяләү критерийларын һәм методикаларын эшли;

Олимпиаданың оештыру комитетына олимпиаданы оештыруны камилләштерү белән бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертә.

5.4. Олимпиада жюрие:

Олимпиадада катнашучыларның олимпиада биремнәрен һәм башка төр сынауларны үтәү нәтиҗәләрен тикшерә һәм бәяли;

Олимпиадада җиңүче, призер һәм номинант кандидатураларын билгели;

Олимпиадада катнашучыларның апелляцияләрен карый һәм аларны карау нәтиҗәләре буенча карар кабул итә.

## VI. КАТНАШУЧЫЛАРНЫ БҮЛӘКЛӘҮ

6.1. Шәхси беренчелектә Олимпиадада җиңүчеләр дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

6.2. Олимпиадада команда ярышларында җиңүче диплом һәм кыйммәтле бүләк белән бүләкләнә.

6.3. Шәхси беренчелектә Олимпиада призерлары (1, 2, 3 дәрәҗә призерлар) дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

6.4. Олимпиада номинантлары грамоталар һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнә.

6.5. III этапта катнашучылар оештыру комитетының рәхмәт хатлары һәм кызыксындыру бүләкләре белән бүләкләнә.

6.6. II этапка узган Олимпиадада катнашучыларга «Кулланучыларның хокукларын яклау» темасы буенча электрон формада Сертификатлар бирелә.

6.7. Кулланучыларның хокукларын яклау буенча республика олимпиадасында актив катнашкан һәм кулланучылар белеме өлкәсендә укучылар әзерләүдә югары дәрәҗә күрсәткән Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары педагоглары оештыру комитетының рәхмәт хатлары һәм кызыксындыру бүләкләре белән бүләкләнә.

6.8. Татарстан Республикасында кулланучылар мәгарифе системасын үстерүгә иң зур өлеш керткән гомуми белем бирү оешмасы диплом һәм бүләк белән бүләкләнә.

6.9. Җиңүчеләрне бүләкләү Олимпиаданың III этабына йомгак ясаганнан соң башкарыла.

## VII. ФИНАНСЛАУ

7.1. Олимпиада уздыру чараларын финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасында каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

«Кулланучыларның хокукларын яклау»
темасы буенча республика олимпиадасын
оештыру һәм уздыру турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

**2019 елда гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Кулланучыларның хокукларын яклау» темасына олимпиадада катнашу өчен гариза (шәхси беренчелек)**

Гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Кулланучыларның хокукларын яклау» темасы буенча олимпиадада ирекле катнашу нияте турында белдерәм.

Мәгълүмат кертү өчен зарури юллар
1. Олимпиадада катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча):
___________________________________________________________________________

2. Катнашучыны әзерләгән укытучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча), фәнен күрсәтеп:

___________________________________________________________________________

3. Язышу өчен фактик адрес:
___________________________________________________________________________

4. Олимпиадада катнашучының элемтә телефоны:
_______________________________

5. Олимпиадада катнашучының электрон почтасы адресы (E-mail):
___________________________________________________________________________

6. Гомуми белем бирү оешмасының исеме (уку йортының исеме һәм №):
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

7. Гомуми белем бирү оешмасының адресы:
___________________________________________________________________________

8. Сыйныф: _____________

«Кулланучыларның хокукларын
яклау» темасы буенча республика
олимпиадасын оештыру һәм уздыру
турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

**Укучылар өчен мәгълүмат**

Гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары Олимпиадада ирекле рәвештә катнаша ала.

Теркәлү формасын тутыручы Олимпиадада катнашучы теркәлү белешмәләренең дөреслеге өчен җаваплы була. Теркәлү формасын дөрес тутырмауга яки теркәлгәндә килеп чыккан техник проблемаларга бәйле дәгъвалар Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителми һәм каралмый. Дөрес булмаган белешмәләр бирелгән очракта һәм гариза тапшырган катнашучы белән элемтәгә чыгу мөмкинлеге булмаган өчен Оештыру комитеты җаваплы түгел.

Белем алу сыйныфын дөрес күрсәтмәгән Олимпиадада катнашучылар Олимпиадада катнашучылар исемлегеннән төшереп калдырыла.

Теркәлү вакытында һәр катнашучы үзенең электрон почта адресын күрсәтергә тиеш. Бер электрон почта адресы буенча ике һәм аннан да күбрәк катнашучы була алмый.

Һәр катнашучы бер генә тапкыр теркәлә ала. Яңадан теркәлү мөмкин түгел.

Мәҗбүри теркәлү юлларын рус телендә, хаталарсыз, дөрес язу кагыйдәләрен саклап тутырырга.

Барлык теркәлү мәгълүматлары кертелгәннән соң, Сез күрсәтелгән электрон почта адресы буенча хат аласыз һәм хатта булган сылтама буенча теркәлүегезне раслыйсыз. Әгәр хат озак килмәсә, Үзегезнең почта тартмаларыгызны игътибар белән тикшерегез.

Әгәр Сез теркәлгән булсагыз, ләкин раслый торган хат алмасагыз, Үзегезнең фамилиягезне, исемегезне һәм атагыз исемен һәм электрон почта адресын күрсәтеп, Оештыру комитетына электрон хәбәр языгыз, теркәлүегезне без үзебез раслarбыз.

Олимпиаданы оештыру комитеты:

Телефон: (843) 277-94-99, 277-94-95 (дүшәмбедән җомгага кадәр, 09.00-17.00 сәгатьләрдә)

Рәсми сайт: https://www.tatzpp.ru/

Электрон почта: Zpp.Olimpiada@tatar.ru

«Кулланучыларның хокукларын яклау»
темасы буенча республика
олимпиадасын оештыру һәм уздыру
турында нигезләмәгә 3 нче кушымта

**2019 елда гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында (команда беренчелеге) «Кулланучыларның хокукларын яклау» темасы буенча олимпиадада катнашу өчен гариза**

Гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында «Кулланучыларның хокукларын яклау» темасы буенча олимпиадада ирекле катнашу нияте турында белдерәбез.

*Мәгълүмат кертү өчен зарури юллар*

1. Гомуми белем бирү оешмасының исеме (уку йортының исеме һәм №):
______________________________________________________________________
____________________________________________________________

2. Гомуми белем бирү оешмасының адресы:
______________________________________________________________________

3. Команда исеме:_______________________________________________

4. Команда әгъзаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча), сыйныфы:

1)____________________________________________________________________
2)____________________________________________________________________
3)____________________________________________________________________
4)____________________________________________________________________
5)____________________________________________________________________

5. Команданы әзерләгән укытучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча), фәнен күрсәтеп:
______________________________________________________________________

6. Укытучының элемтә телефоны:_______________________________

7. Укытучының электрон почта адресы (E-mail):
______________________________________________________________________